INNOVATIVE TECHNOLOGIES
ИННОВАЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ

# 2015-2017
# ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ БУЕНЧА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЕЛНЫҢ ИҢ ЯХШЫ ЭКСПОРТЕРЫ

# ПРЕДПРИЯТИЕНЕҢ ЕЛ САЕН ТАБЫШ АЛУ КҮЛӘМЕНЕҢ УРТАЧА ҮСЕШЕ КИМЕНДӘ 20% ТӘШКИЛ ИТӘ

# 2017 ЕЛДА 1 720 000 ЛИТР ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРЕЛДЕ

# ПРОДУКЦИЯ БАРЧА КӨНЧЫГЫШ ЕВРОПА, АЗИЯ ҺӘМ ЛАТИН АМЕРИКАСЫ ИЛЛӘРЕНӘ ЭКСПОРТКА ҖИБӘРЕЛӘ

# "ИННОВАЦИЯЛЕ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР" ҖЧҖ РОССИЯДӘ ИННОВАЦИЯЛЕ ЯКЛАГЫЧ КАПЛАМАЛАР ЭШЛӘҮ ҺӘМ ҖИТЕШТЕРҮ БУЕНЧА АЛДЫНГЫ ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРНЕҢ БЕРСЕ БУЛЫП ТОРА

- **ЯКЛАГЫЧ КАПЛАМАЛАР ҖИТЕШТЕРҮНЕҢ 5 ТӨП ЮНӘЛЕШЕ.**
- **ТӨРЛЕ КОНКУРСЛАРДА КАТНАШКАН ӨЧЕН ДИСТӘЛӘРЧӘ БҮЛӘК.**
- **ШӘХСИ ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ ЛАБОРАТОРИЯСЕ.**
- **ҖИТЕШТЕРЕЛӘ ТОРГАН БАРЧА ПРОДУКТЛАР АВТОР ХОКУКЛАРЫ БЕЛӘН ЯКЛАНГАН.**
- **БАРЫ ТИК ШӘХСӘН ЭШЛӘНГӘН ТЕХНОЛОГИЯЛӘРДӘН ҺӘМ РЕЦЕПТУРАЛАРДАН ГЫНА КУЛЛАНЫЛА.**

INNOVATIVE TECHNOLOGIES
ИННОВАЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ

# БЕЗНЕҢ ПРОДУКЦИЯ

# RE-FLAME

**Янгын барлыкка килгән очракта терәк булып торучы, югары температура йогынтысына дучар ителүче металл конструкцияләр деформацияләнә башлый. Әлеге хәл бик тиз вакыт аралыгында бинаның ишелүенә китерә. Җылытканда күләмен 50 мәртәбәгә кадәр зурайту мөмкинлеген бирә торган үзлекләргә ия булган, уттан яклаучы күптергеч каплама киңәя-киңәя, җылылык үткәрү коэффициенты түбән булган, уттан саклаучы күбек хасил итә, ул ялкынның һәм температураның металл өслегенә җитүенә каршы тора.**

**Каплама 120 минутка кадәр ялкын температурасын тоткарлап тора ала. Шушы вакыт эчендә бинадан персоналны тулысынча эвакуацияләү һәм объектка экстрен хезмәтнең килүе күздә тотыла, соңгысы бина ишелә башлаганчы ялкынны сүндереп өлгерәчәк.**

**Янгыннан яклаучы RE-FLAME капламасы югары технологияле, оптималь дәрәҗәдә тулысынча катнаштыру һәм кыру өчен компонентларны эшкәртү мөмкинлеген бирүче җайланмада бары тик заманча компонентларны кулланып кына әзерләнә. Шунысын да билгеләп узарга кирәк, янгыннан яклаучы RE-FLAME составына алюминий оксидының наноструктурлаштырылган кисәкчәләре (нанопластинкалар) керә, алар капламаның югары дәрәҗәдә озакка чыдамлылыгын, ныклылыгын һәм һава дымына тотрыклылыгын тәэмин итә.**




*Төргәкләнеше – 3, 10, 20 кг чиләкләр.*

INNOVATIVE TECHNOLOGIES
ИННОВАЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ

# RE-FLAME СТАНДАРТ

**теләсә нинди материаллардан ясалган өслекләрнең җылылыгын изоляцияләү өчен универсаль модификация.**

**Үтә юка RE-THERM җылылык изоляциясе – ул фән-техника прогрессында иң соңгы казанышларга нигезләнеп ясалган каплама. Әлеге состав катламның калынлыгы 1 миллиметр булганда да шактый җылылык изоляцияләү нәтиҗәсен бирә, үзенең нәтиҗәлелеге буенча калынлыгы 50 миллиметрлы классик җылылык изоляциясе катламын куллану белән чагыштырып була. Асылы буенча RE-THERM җылылык изоляциясе лак-буяу материалыннан гыйбарәт, теләсә нинди өслеккә (фасадка яисә йортның эчке як стенасына, трубага, резервуарга һ.б.) сылаганнан соң төгәл җылылык изоляциясе кебек хезмәт итәргә сәләтле юка (1-3 мм) пленка хасил итә.**

**Җылылык изоляцияләүче RE-THERM полимер капламасы вакуумлаштырылган керамик микросфералардан (күләме 10 мкм башлап 50 мкм кадәр) һәм буш куыклы силикон микросфералардан (диаметры 30 мкм башлап 100 мкм кадәр) тора, алар полимер ялгагыч, пигментлар, антипиреннар, пластификаторлар һәм максатчан бүтән кушылдыклар катнашмасында үлчәнгән торышында тора. RE-THERM җылылык саклагыч капламаларның мондый составы аларны җиңел, сузылучан һәм UF-нурланышка, атмосфера явым-төшемнәре йогынтыларына һәм температура үзгәрешләренә карата тотрыклы итә.**




***Төргәкләнеше –***
***3, 10, 20 л. чиләкләр.***

INNOVATIVE TECHNOLOGIES
ИННОВАЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ

# Вертикаль RE-FLAME

**Югары дәрәҗәдә ябышу үзлегенә ия, стена һәм вертикаль конструкцияләрне җылыту өчен әйбәт.**

**Үтә юка сыек RE-THERM җылылык изоляторларының җылылыкны үткәрү коэффициенты уникаль дәрәҗәдә түбән, ул әлеге составларны "классик" җылыткычлар белән чагыштырганда дистәләрчә мәртәбә нәтиҗәлерәк итә, шуның нәтиҗәсе буларак җылылык изоляцияләүдә кулланыла торган катламның калынлыгын феноменаль дәрәҗәдә киметү мөмкин була. RE-THERM атмосфера йогынтыларына югары дәрәҗәдә каршы тора алучанлыгы аны өстәмә яклагычлардан – трубаүткәргечләрне һәм башка металл өслекләрне тышлау чараларыннан һәм киртәләп торучы конструкцияләрдә тышлагыч материалларны куллану зарурлыгыннан башка гына куллану мөмкинлеген бирә.**

**Стенага сөртелгән RE-THERM капламасы югары дәрәҗәле җылылык изоляцияләү материалы булуы өстенә, стенаның үзен дә тышкы факторларның тискәре йогынтысыннан саклаучы яклагыч состав та булып тора.**




***Төргәкләнеше – 3, 10, 20 л. чиләкләр.***

INNOVATIVE TECHNOLOGIES
ИННОВАЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ

# RE-THERM Ингибитор

**Металл өслекләрне тутыгу күренешләреннән нәтиҗәле саклый.**

**Үтә юка сыек RE-THERM җылылык изоляциясен чук, валик, бөркегеч, шпатель кебек стандарт буяу кораллары ярдәмендә сөртәләр. Идеаль сайлап алынган компонентлар, RE-THERM җылылык изоляцияләү капламасы әзерләү җайланмалары һәм технологиясе аңа, җылылыкны изоляцияләү белән берлектә, гидроизоляция үзлекләрен дә бирә, ә билгеле бер шартларда тавыштан изоляцияләү үзлеге дә юк түгел. RE-THERM капламасы менә инде берничә ел дәвамында төрле объектларда актив файдаланыла һәм киң кулланылыш тәҗрибәсенә ия. Үтә юка сыек RE-THERM җылылык изоляциясен куллану тәҗрибәсе аның белән җылытылган объектларның күп елларга үзгәрешсез торышта булуы хакында сөйли, ә аларны эксплуатацияләүче кешеләр җылытуның җитәрлек дәрәҗәдә булмавына, төзелеш конструкцияләренең юешләнүенә һәм күгәрүенә бәйле проблемалар турында мәңгелеккә онытkан дигән сүз.**

**Башка үзенчәлекләреннән тыш, үтә юка сыек RE-THERM җылыткычы янгынга каршы материал буларак та хезмәт итә. Әлеге составлар ике – начар янучан һәм янмый торган (куллану өлкәләренә һәм бурычларына карап) төрдә чыгарыла. Үз материалларын булдырганда безнең компания һәрвакытта да әйләнә-тирәлеккә зыян салмый торган продукт ясау турында уйлап эш итә һәм сыек RE-THERM җылылык изоляциясе дә искәрмә булып тормый!**




***Төргәкләнеше –***
***3, 10, 20 л. чиләкләр.***

INNOVATIVE TECHNOLOGIES
ИННОВАЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ

# RE-THERM Антифриз

**-40 С температурага кадәр сакланырга мөмкин.**
**Эрегәннән соң үзлекләрен югалтмый.**

**RE-THERM җылылык саклау капламаларын куллану тармаклары һәм объектлары турында сөйләгәндә, аларның исәбе-хисабы юк дияргә була. Аларның берничәсен генә санап үтик:**

- **Стеналарның, балконнарның һәм түшәмәләрнең бозланып кату күренешләрен бетерү.**
- **Ян-якларны җылыту, идәннәрне җылыту һәм биналарның эчке як стеналарын җылыту.**
- **Стеналарда һәм киртәләп торучы башка конструкцияләрдә конденсатны бетерү.**
- **Трубаүткәргечләрне, технологик җайланмаларны, резервуарларны һәм бикләгеч арматураларны җылылык белән изоляцияләү.**
- **Трубаүткәргечләрнең металл өслекләрендә булган конденсат күләмен киметү яисә тулысынча бетерү.**
- **Судноларда һәм транспортның бүтән төрләрендә бүлгеләрне һәм корпусларны җылылык белән изоляцияләү.**
- **Трубаүткәргечләрдән һәм җайланмалардан җәрәхәт алу куркынычын киметү (хезмәт күрсәтүче персоналның пешү мөмкинлеген юкка чыгару).**
- **Түбәләрне, подвалларны, техник катларны (чорма бүлмәләрен җылыту һ.б. )**




***Төргәкләнеше –***
***3, 10, 20 кг чиләкләр.***

INNOVATIVE TECHNOLOGIES
ИННОВАЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ

# RE-THERM Фрост

**Төрле, шул исәптән югары температура йогынтысына дучар ителгән, конструкцияләргә сөртү өчен билгеләнгән. Сөртү шарты: һава температурасы -20С ким булмаска тиеш.**

**Йомгак ясап, RE-THERM капламнары ия булган төп өстенлекләрне биләгеләп үтәргә мөмкин:**

- **Җылыту белән бәйле эшләрнең гадилеге, җайлылыгы һәм югары тизлектә башкарылуы.**
- **Трубаүткәргечләргә өстәмә катлам сөртү зарурлыгы юк.**
- **Фасадларда җылылык белән изоляцияләү катламын тышлау зарурлыгы юк.**
- **Трубаүткәргечләрне RE-THERM белән җылытканда - тутыгудан саклау, җылылыкны, пардан изоляцияләү һәм каплап торучы катлам!**
- **Өслек торышын даими тикшереп тору мөмкинлеге.**
- **Объектка өстәмә авырлык басымы бирми һәм җылытыла торган объектның күләмен арттырмый.**
- **Тышкы яктан зәвыкълы күренә һәм җиңел генә төрле төсләргә керә.**
- **Тышкы барча диярлек йогынтыларга югары каршы торучанлык дәрәҗәсе кимендә 15 елга чыдам булуын тәэмин итә.**




***Төргәкләнеше – 5, 10, 20 л. чиләкләр.***

# R-COMPOSIT

**Куллануның киң спектрына ия булган битумсыз полимер материал. Уникаль үзлекләре бар – югары дәрәҗәдә нык, суның статик йогынтысына, тоз эретмәләренә һәм селтеләргә каршы чыдам.**

**Гидроизоляцияле R-COMPOSIT капламасы – ул куллануның киң спектрына ия булган битумсыз полимер материал. Әлеге продукт иң заманча технологияләрне һәм материалларны кулланып эшләнде. R-COMPOSIT уникаль үзлекләргә ия – югары дәрәҗәдә нык, суның статик йогынтысына, тоз эретмәләренә һәм селтеләргә каршы чыдам.**
**Гидроизоляцияле R-COMPOSIT капламасы 1 мкм алып 4 мкм кадәр зурлыктагы, латекс, максатчан өстәмәләр, пластификаторлар, антипиреннар һ.б. полимер композициясендәге мәрмәр микрокисәкләреннән (алар капламаның тышкы факторлар йогынтысына карата югары дәрәҗәдә чыдам булуын тәэмин итә) торучы катнашмадан гыйбарәт.**

**R-COMPOSIT куллану өлкәсе – яссы түбәләрнең барлык төрләре (яңалары да, эксплуатациядә булганнары да), санузелларны һәм ашханә бүлмәләрен капма-каршы гидроизоляцияләү, бассейннарны, фундаментларны, теләсә нинди киртәләп торучы, су үтеп керүдән саклауны таләп итә торган конструкцияләрне гидроизоляцияләү.**
**Капламаның ак төсе кояш яктылыгын чагылдыра, бу исә конструкцияләрнең югары катларын кондиционерлау өлешендә экономияләү мөмкинлеген бирә.**




*Төргәкләнеше –*
*10, 20 кг чиләкләр.*

# R-COMPOSIT RADON

**R-COMPOSIT™ RADON - ул латекс-акрил нигезендә мәрмәр белән модификацияләнгән, суда эретелгән катнашма рәвешендә, магнезит яисә шунгитлы магнезит рәвешендәге махсус кушылдыклары булган уникаль полимер материал. Полимерлаштырылганнан соң каплама бүлмәгә Радонның 222 үтеп керү дәрәҗәсен 98%ка кадәр киметә.**

**R-COMPOSIT™ RADON материаллары буяу кебек күренә, өслеккә чук, шпатель яисә валик ярдәмендә сөртелә, ә югары басымлы һавасыз буяу пультыннан файдалану (зур мәйданнарда бу максатка ярашлы булыр) хезмәт җитештерүчәнлеген дистәләрчә мәртәбәгә арттыра.**
**Яхшы ябышучан булуы белән аерылып тора (сөртү нигезе бетон, фундамент блоклар һәм түшәмә плитәләре, теләсә нинди штукатуркалар, кирпеч, керамик плитә, гипс, ГКЛ, ДВП булырга мөмкин).**

**R-COMPOSIT™ RADON материалларын балалар һәм медицина учреждениеләрендә, азык-төлек җитештерү урыннарында, теләсә нинди сәнәгый, иҗтимагый һәм торак биналарда, радоннан якланырга тиешле теләсә кайсы объектларда куллану өчен киңәш ителә.**
**R-COMPOSIT™ RADON материаллары "Инновацияле технологияләр" ҖЧҖ (Казан ш.) радиоактив радон газының куркынычлы йогынтысыннан, геопатоген факторлардан яклау, табигый һәм техноген электр-магнит нурланышларның һәм зыянлы экологик факторларның тәэсирен киметү өчен махсус эшләнде һәм җитештерелә.**




***Төргәкләнеше – 10, 20 кг чиләкләр.***

INNOVATIVE TECHNOLOGIES
ИННОВАЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ

# S-COMPOSIT STANDART

**Төрле максатларда куллану өчен яклагыч капламалар сериясе**

**Алифатик полиизоцианат һәм органик эретмәдәге полиол нигезендә ясалган, һава дымында катылана торган бер компонентлы полиуретан состав.**
**Бетон, металл, агач өслекләрнең яклагыч лак-буяу капламы буларак кулланыла. Тулысынча кипкән каплама югары дәрәҗәдә чыдам, сузылучан, шулай ук сөртелүгә һәм химик йогынтыларга каршы тотрыклы. Кояш яктысы йогынтысы астында ныклылык үзлекләрен югалтмыйча, капламаның төсе саргаерга мөмкин.**
**S-COMPOSIT STANDART™ түбәндәгеләр өчен билгеләнгән:**
**стеналарны, түбәләрне, бетон, агач һәм металл эшләнмәләрне, конструкцияләрне механик һәм химик йогынтылардан саклау өчен, шулай ук бетон идән өчен таушалуга чыдам декоратив каплама сыйфатында;**
**төче һәм тозлы су, нефть һәм нефть продуктлары йогынтысына дучар ителә торган металл (чистартылган яисә тутык калдыклары белән), бетон, тимер-бетон һәм агач өслекләрне тутыгуга каршы, гидроизоляцияле һәм таушалуга чыдам өслек белән каплау өчен.**
**Өстенлекләре:**
**Югары дәрәҗәдә таушалуга чыдам һәм химик йогынтыларга каршы торучан;**
**Җайлы гына һәм гади генә сөртелә;**
**Тигез ярым-ялтыравык өслек хасил итә.**
**- 30С градуслы температурага кадәр сөртергә кирәк.**
**Тиз катa һәм эксплуатацияләнә башлый**




*Төргәкләнеше –*
*5, 10, 20 кг чиләкләр.*

INNOVATIVE TECHNOLOGIES
ИННОВАЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ

# S-COMPOSIT CRYSTAL

S-COM CRYST

Бетон өслекләрне, машина төзелеше эшләнмәләрен, гидротехника корылмаларын, төрле билгеләнештәге металл конструкцияләрне декоратив буяу-яклау өчен юка катлы ике компонентлы полиуретан каплама.

УШ-нурланышка тотрыклы булуы составның аерып торучы үзенчәлеге булып тора, каплама саргаймый һәм ачык атмосфера шартларында декоратив сыйфатларның барысын да тулысынча саклый. Капламаның экологияле һәм химик инертлы булуы аркасында ул азык-төлек продуктлары һәм эчә торган су белән турыдан-туры бәйләнештә дә кулланыла ала.

*Төргәкләнеше –*
*6,74, 13,48, 26,96 кг комплектлар.*



# S-COMPOSIT ZINC

S-COM ZINC

алифатик полиизоцианат һәм органик эретмәдәге полиол нигезендә ясалган полиуретан состав, һава дымында ката торган, алюминий диоксидының һәм кремний оксидының вак таркалган цинк порошогы кушылган нанокисәкчекләре. Металл өслекләр өчен тутыгуга каршы яклагыч катлам буларак кулланыла. Тулысынча кипкән өслек югары дәрәҗәдә нык, сузылучан, шулай ук сөртелүгә һәм химик йогынтыга каршы тотрыклы. Материалда булган тутыгуга каршы тору үзлекләре нәтиҗәлелеге буенча заводта цикланган материалдан бер дә калышмый. 200 мкм (0,2 мм) кадәр калынлыкта тутык катламы булган өслекләргә сөртелергә мөмкин. Капламаның экологияле һәм химик инертлы булуы аркасында ул азык-төлек продуктлары һәм эчә торган су белән турыдан-туры бәйләнештә дә кулланыла ала.




*Төргәкләнеше – 5, 20 кг комплектлар.*

# S-COMPOSIT CARBON

S-COM
CARBO

өч катлы полиуретан каплама, төрле өслекләрне, механик һәм химик йогынтылардан саклауны тәэмин итә һәм су белән элемтәгә керүдән саклый. Тулысынча кипкән каплама агрессив химик матдәләрнең күпчелегенә каршы тора ала, сыек тирәлектә (суда, серкәләрдә, нефтьтә) даими рәвештә кимендә 30 ел дәвамында бер үзгәрешсез саклана. Өслектә ачык кара төсендәге ялтыравык тышча хасил итә. Капламаның экологияле һәм химик инертлы булуы аркасында ул азык-төлек продуктлары һәм эчә торган су белән турыдан-туры бәйләнештә дә кулланыла ала.




*Төргәкләнеше –*
*5, 20 кг комплектлар.*

INNOVATIVE TECHNOLOGIES
ИННОВАЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ

# S-COMPOSIT TOP-COAT

S-COM
TOP-CO

ике компонентлы полиуретан каплама. Югары дәрәҗәдә атмосферага һәм таушалуга каршы чыдам. Зур дәрәҗәдә ялтыравыклы  һәм төсен саклый торган пленка хасил итә. Бетон, металл, агач әслекләр өчен яклагыч-декоратив финиш катламнары буларак кулланыла. Кипкәннән соң каты, шул ук вакытта сузылучан тышча барлыкка китерә, механик һәм химик йогынтыларга каршы тора, күркәм тышкы кыяфәтле һәм атмосферага каршы югары дәрәҗәдә чыдамлы, кояш яктысында саргаймый. Капламаның экологияле һәм химик инертлы булуы аркасында ул азык-төлек продуктлары һәм эчә торган су белән турыдан-туры бәйләнештә дә кулланыла ала.




*Төргәкләнеше –*
*5, 20 кг комплектлар.*

# S-COMPOSIT
# TOP-COAT (ZN)

S-COM
TOP-CO

юка катлы полиуретан каплама. Металл өслекләрне тутыгуга каршы яклагыч сыйфатында кулланыла. Тулысынча кипкән каплама югары дәрәҗәдә нык, сузылучан, атмосферага каршы торучан, сөртелүгә һәм химик йогынтыларга каршы тотрыклы, кояш яктысында саргаймый. Нәтиҗәлелеге буенча каплама заводта цинкланганыннан берничек тә калышмый. Калынлыгы 200 мкм (0,2 мм) кадәрле тутык катламы булган өслекләргә сөртелергә мөмкин. Капламаның экологияле һәм химик инертлы булуы аркасында ул азык-төлек продуктлары һәм эчә торган су белән турыдан-туры бәйләнештә дә кулланыла ала.




*Төргәкләнеше – 5, 20 кг комплектлар.*

INNOVATIVE TECHNOLOGIES
ИННОВАЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ

# S-COMPOSIT TOP-COAT (CB)

S-COM
TOP-CO

өч компонентлы, полиуретан, юка катлы каплама. Химик яктан тоз эретмәләренә, серкәләргә һәм тирәлек серкәләренә  каршы югары дәрәҗәдә тотрыклы, умырылуга каршы торучанлыгы югары, атмосферага карата чыдам, кояш яктысында саргаймый. Каплама куе кара төстә һәм ялтыравыклы. Капламаның экологияле һәм химик инертлы булуы аркасында ул азык-төлек продуктлары һәм эчә торган су белән турыдан-туры бәйләнештә дә кулланыла ала




*Төргәкләнеше –*
*5, 20 кг комплектлар.*

INNOVATIVE TECHNOLOGIES
ИННОВАЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ

# NANO-FIX КОНЦЕНТРАТ

# NANO-КОНЦЕ

бу уникаль, экологик чиста, махсус полимер кушылдыклары булган, махсус акрил сумала композициясе нигезендә ясалган вак-вак таркалмалы наносеңдермә. Материал төрле күзәнәкле һәм микрокүзәнәкле материаллардан торучы нигезләрне тузансызландыру, ныгыту һәм катылыгын арттыру, материаллар арасында ябышу үзлеген яхшырту, декоратив һәм структур штукатурка сөртер алдыннан нигезләрне әзерләү өчен кулланыла. Су нигезендә ясалган югары катнашмалы сыек катнашма рәвешендә чыгарыла һәм структурасында югары сыйфатлы махсус полимерларның нанозурлыктагы (10-50 нанометр) кисәкчекләре бар.

*Төргәкләнеше –*
*1 кг шешә, 5 кг канистра.*



# NANO-FIX MEDIC

# NANO-MEDIC

кешеләр һәм әйләнә-тирә мохит өчен куркынычсыз булган соңгы буын антисептик препаратларның куллану өчен әзер булган судагы измәсе, зарарлы микрофлораны бастыру өчен нәтиҗәле чара булып тора, тиз арада һәм нәтиҗәле итеп күгәрекне бетерү мөмкинлеген бирә, бактерияләргә һәм йогыш чыганакларына карата актив көрәшә. Эчендә 10-50 нанометр зурлыгындагы полимер кисәкләре бар, шуның ярдәмендә антисептик күп еллар дәвамында эшкәртелгән өслектә кала, җил һәм су аркасында таркалмый.




*Төргәкләнеше –*
*1 кг шешә, 5 кг канистра.*

# NANO-FIX PRIMER

# NANO-PRIMER

пластикка, төсле металл өслекләргә, шулай ук тутыкмый торган корыч, цинкланган тимер, углеродлы корыч һ.б. өслегенә ябыштыруны тәэмин итү өчен билгеләнгән. Үзенең составы буенча нанозурлыгындагы пластификаторлар һәм модификаторлар кушылган акрил сумалаларның һәм органик эретмәләрнең югары катнашмалы измәсен тәшкил итә.

*Төргәкләнеше –*
*5, 10, 20 кг чиләкләр.*




INNOVATIVE TECHNOLOGIES
ИННОВАЦИОННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ

# NANO-FIX ANTICOR

тутыктан саклауга каршы принципиаль дәрәҗәдә яңа алым, тимер оксиды компонентлары һәм кристаллик рәшәткә атомнары белән бергә молекулаларның үзара катлаулы бәйләнешеннән гыйбарәт.

Каплама микро-ярыкларга һәм металл тишекләренә үтеп керү үзлегенә ия, бер үк вакытта тутыга башлау процессларын бастыра. Шундый тәэсир итү механизмы 100 микронга кадәр тутык катламын NANO-FIX  ANTICOR белән “тыгызлап бәйләү” мөмкинлеген бирә. Тутыкны, грунтны һәм финиш эмален үзгәртеп кору үзлекләрен берләштерә.




*Төргәкләнеше –*
*5, 10, 20 кг чиләкләр.*